Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

17 март, 2023 ел № 4

Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге уставы, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2023 елның 10 мартындагы җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирергә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:040422:1475, мәйданы 501 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы, Клубничная урамы, 36 - «4.4 Кибетләр».

- ж/к кадастр номеры 16:33:040422:1484, мәйданы 501 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы, Малиновая урамы, 35 - «4.4 Кибетләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһаувов